# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Кургем авылында, Куныр авыл җирлеге**
**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башкарма комитеты**

2024 елның 24 март № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Куныр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 25 статьясына ярашлы рәвештә җыен беркетмәсе төзелде Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Куныр авыл җирлегенең Кургем авылы торак пунктында гражданнарны:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Куныр авыл җирлеге Кургем авылында гражданнар җыены карарына 29.12.2023 ел, №2 үзгәрешләр кертергә:

2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту: Кургем торак пунктының Садовая урамындагы юлны ремонтлау,

ремонт, коймалар төзү, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү: Кургем торак пункты зиратында агачлар кисү.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Куныр авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән Балтач муниципаль районының рәсми сайтында халыкка игълан итәргә. baltasi.tatarstan.ru. Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында. pravo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет Рәисе Р.О.Егоров